Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Богородский авыл җирлеге башлыгы
**КАРАРЫ**

22 август, 2023 ел № 21

«Көек авылындагы җир кишәрлекләреннән шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башлыгы карары проекты буенча Көек авылында иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлегендә 2017 елның 21 августындагы 80 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлегендә (2017 елның 14 декабрендәге 94 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 108 номерлы, 2019 елның 2 октябрендәге 156 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 62 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 70 номерлы үзгәрешләре белән) иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, түбәндәге гаризалар нигезендә карар бирәм:

1. «Көек авылындагы җир кишәрлекләреннән шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башлыгы карары проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләргә (алга таба - Проект) (кушымта).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия);

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2023 елның 31 августында 11.30 сәгатьтә Питрәч муниципаль районы Советының кече залында, ТР, Питрәч районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч ав., Совет ур., 18 й. адресы буенча.

2.3. Авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес: Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты, 422774, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский ав., Үзәк ур., 57Б/1 йорт (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.);

2.4. Богородский авыл җирлеге халкына җиткерү максатларында 2023 елның 28 августында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский ав., Үзәк ур., 57Б/1 йортында проектның демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясе оештырыла (дүшәмбе-җомга 8-00 сәгатьтән 12-00 сәгатькә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Комиссиягә:

3.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру йомгаклары буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә;

3.2. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен Питрәч муниципаль районы Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга;

3.3. «Вперед» («Алга») газетасында иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында хәбәр бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов

СОВЕТ БОГОРОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БОГОРОДСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * ИНН 1633000835

Богородский авыл җирлеге башлыгы карарына кушымта
22.08.2023 ел № 21

Проект

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Богородский авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

___ _____ 2023 ел № __

Көек авылындагы җир кишәрлекләреннән шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенең 2023 елның ___ _________ ___ номерлы иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә әзерләнгән тәкъдимнәрен исәпкә алып, карар бирәм:

1. Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә:

- ж/к кадастр номеры 16:33:140406:2231, мәйданы 1 274 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Көек авылы, Умырзая ур., 1 ж/к - «Автомобильләр ремонтлау » индивидуаль торак зонасында (Ж1).

- ж/к кадастр номеры 16:33:021126:1887, мәйданы 1 094 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Көек авылы - « Бакчачылык тармагын алып бару» индивидуаль торак зонасында (Ж1).

- ж/к кадастр номеры 16:33:021126:1886, мәйданы 1 355 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Көек авылы - « Бакчачылык тармагын алып бару» индивидуаль торак зонасында (Ж1).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов